ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 13 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 24 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 15 пункт өстәргә:
“15) Федераль законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.”;

2) 13 статьяда:
а) 1 өлештә “шул исәптән җир кишәрлекләрен” сүзләреннән соң “(шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, яшелчәчелек, бакчачылык, индивидуаль торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән тыш)” сүзләрен өстәргә;
б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;
в) 3 өлештә “2 өлешендә” сүзләрен “$4^1$ өлешендә” сүзләренә алмаштырырга;
г) 4 өлешнең 1 пунктында “Россия Федерациясе субъектларының дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы $2^1$ өлеше” сүзләрен “Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана

торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының $39^3$ статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда" сүзләренә алмаштырырга, аңа түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: "Күрсәтелгән исемлеккә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына арендага бирелгән җир кишәрлекләреннән тыш, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{11}$ статьясындагы 8 пунктының 1 – 10, 13 – 15, 18 һәм 19 пунктчаларында каралган җир кишәрлекләре керми.";

д) $4^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$4^1$. Әлеге статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, аны "Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Россия Федерациясе Җир кодексының $39^3$ статьясындагы 2 пунктының 6, 8 һәм 9 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары милкенә түләүле рәвештә читләштерүдән тыш, сату тыела. Күрсәтелгән мөлкәткә карата аннан файдалану хокукларын башкаларга биреп тору, аннан файдалану хокукларын залогка бирү һәм мондый мөлкәттән файдалану хокукларын хуҗалык эшчәнлегенең теләсә-кайсы башка субъектларының устав капиталына кертү, мондый мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча хокукларны һәм вазыйфаларны өченче затларга тапшыру (яңадан наемга бирү), субарендага бирү тыела, моңа кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар тарафыннан мондый мөлкәтне кече һәм урта эшкуарлык субъектларына субарендага бирү һәм "Конкуренцияне яклау турында" 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның $17^1$ статьясындагы 1 өлешенең 14 пунктында каралган мөлкәтне субарендага бирү очрагы керми.";

е) түбәндәге эчтәлекле $4^2$ өлеш өстәргә:

"$4^2$. Дәүләт унитар предприятиесенә хуҗалык алып бару яисә оператив идарә хокукында, дәүләт учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте, күрсәтелгән предприятие яисә учреждение тәкъдиме буенча һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле мөлкәт белән алыш-бирешне килештерүгә вәкаләтле органы ризалыгы белән, мондый мөлкәтне кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга аңа хуҗа булу һәм (яисә) аннан файдалану өчен бирү максатларында әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә шушы статьяның 4 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән исемлеккә кертелергә мөмкин.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 13 октябрь
№ 70-ТРЗ